РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Глава**
**Уразлинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Уразлы**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Мира, 7,с. Уразлино, 422838
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

Тынычлык урамы, 7,Уразлы авылы, 422838,
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 ноябрь 2021 года** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Сатлыган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 9 декабрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Сатлыган торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Сатлыган авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар,көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

* Сатлыган  авылы эчендәге юлларны ремонтлау(таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

* җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

* Сатлыган  авылында юлларны тигезләү, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

"ӘЙЕ"                    “ЮК”

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) :

- ТР, Кама Тамагы районы, Уразлы авылы, Тынычлык  урамы, 7;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече  урамы, 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Салтыган авылы, Урта  урамы, 1,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Уразлы авыл җирлеге**
**башлыгы                                                      М.Г.Хәмидуллин**